РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет Тойкинского
сельского поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Джалиля, д.19, с.Тойкино, 423302,
тел./факс (885592)45-0-89
E-mail: Toy.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге
башкарма комитеты

Җәлил ур.,19 йорт, Азнакай районы, Туйкә
авылы, 423302
тел./факс (885592)45-0-89
E-mail: Toy .Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» гыйнвар 2026ел.** **№ 3**

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә , Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2026елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9 678,63 (тугыз мең алты йөз җитмеш сигез сум алтмыш өч тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми

сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №1 нче кушымта
«30» гыйнвар 2026№ 3

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4200,00 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **4** | **Барлыгы** | **9 678,63** |

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районының Туйкә
авыл җирлеге Башкарма комитеты
карарына №2 нче кушымта
«30» гыйнвар 2026 №3

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
«Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1 600,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 600,00 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **5** | **Барлыгы** | **9 678,63** |